# «Артек» истәлекәре

Әхмәдиева (Усманова)Гүзәл Гаваз кызының шәхси архивыннан алынды, Урманасты Шынталысы



“Унөч яшьләр тирәсендә миңа, ниндидер могҗиза белән, «Артек» пионер лагеренда ял итәргә туры килде. Аюдаг итәгендә, Кара диңгез буенда җәйрәп яткан бу җәннәт почмагында кемнәр генә, нинди генә милләт балалары юк иде. Безнең дружина үзе генә дә СССРның нәни бер моделен хәтерләтә иде. Эстоннар, литвалылар, латышлар, украиннар, руслар, белоруслар, гөрҗиләр, әрмәннәр, әзәриләр... Төрле конкурс-бәйгеләрдә катнашып кечкенә бүләк алуыма кош тоткандай сөенеп бик канәгать кайттым лагерьдан.”(Әхмәдиева Гүзәл сөйләгәннәрдән)



Лагерь дөньяның җәннәткә тиң бер почмагына — Кара диңгез буена, Аюдаг итәгенә урнашкан.



Биредә ел әйләнәсе — кояш, яшеллек, диңгез...



“Артек” балачакның иң гүзәл бер хатирәсе булып күңелдә саклана.





**Артектагы ал учаклар-**
**Дуслык, шатлык учаклары.**
**Учактай гел балкып торыр**
**Балачакның бу чаклары.**
**Ал учаклар якты өсти**
**Безнең изге теләкләргә.**



**“Артек”тагы учаклардан**
**Ут алабыз йөрәкләргә.**
**Очкыннарын сүндермичә**
**Ялкын итеп үрләтербез.**
**Шул ялкынны учак итеп**
**Өр-яңадан дөрләтербез!**